| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2020 п.г.т. Алексеевское № 233

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Алексеевск шәһәр җирлеге Советының**
**2011 елның 29 гыйнварындагы**
**108 номерлы «Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Алексеевск ш. т. б. җирдән файдалану һәм**
**төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»**
**гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге, 2020 елның 13 апрелендәге гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен (тәкъдимнәрен) исәпкә алып,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 2011 елның 29 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск ш. т. б. җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында: Алексеевск штб төньяк-көнчыгыш өлешендә, Юбилей ур., 7Б й., Р-1 территориаль зонасының бер өлеше (гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы), гомуми мәйданы 0,7 гектар булган, ПК-1 территориаль зонасына (җитештерү һәм коммуналь-склад объектлары зонасы) үзгәртергә. (Кушымта).

Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:05:010103:441.

Әлеге территориаль зона урнашкан Кадастр кварталы: 16:05:010103.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Алексеевск шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары О.В. Зубриловка йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск
шәһәр җирлеге Советының
20.04.2020 елның 233 номерлы
карарына кушымта

